РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» февраль 2021 ел г. Альметьевск № 07

Әлмәт шәһәре Башкарма
комитетының «Татарстан Республикасы
Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының
резерв фонды акчаларын тоту тәртибе
турындагы нигезләмәне раслау хакында»
2012 елның 06 июлендәге 12 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2021 елның 13 гыйнварындагы 09/13-09/49 номерлы хаты нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 06 июлендәге 12 номерлы карарына (Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 27 декабрендәге 34 номерлы, 2021 елның 15 гыйнварындагы 01 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

3 бүлекнең 3.1. пунктындагы 4 абзацында «(сәламәтлек саклау учреждениеләре тәкъдиме буенча)» сүзләрен өстәргә;

4 бүлекнең 4.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Резерв фондыннан акча бүлеп бирү шарты булып, салым, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына кире кайтару буенча кичектерелгән бүтән бурыч булмау тора.

Әлеге пунктның беренче абзацы 3 бүлекнең 3.1 пунктының икенче, өченче, дүртенче, бишенче, җиденче һәм сигезенче абзацларында каралган чыгымнарны финанслауга кагылмый»;

4.3. пунктта «Учреждение» сүзен «Физик затлар, учреждениеләр» сүзләренә алмаштырырга».

2. Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 06 июлендәге 12

21 013

номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 15 гыйнварындагы 01 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе — Л.Ф. Вәлиев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ